ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**15.11.2022г.**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3141**

2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^2$ статьясындагы 4 пунктының дүртенче абзацы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары, әлеге карар кушымтасы нигезендә беркетелгән, исемлеген расларга.
2. Әлеге карар, 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорындагы бюджеттан башлап, Зеленодольск муниципаль районы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, ММЧ белән элемтә бүлегенә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының төп администраторлары исемлеген раслау турында» 2021 елның 10 ноябрендәге 2825 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. А.В.Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2022 елның
15 ноябрендәге 3141нче карарына
кушымта

**2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары баш администраторлар исемлеге**

| Башлык коды | Чыганакларның төркем, төркемчә, статья һәм төрләре коды | Атамасы |
|---|---|---|
| **803** | **Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы** | |
| 803 | 01 06 01 00 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль милектә булган акцияләр һәм капиталда катнашуның башка рәвешләре |
| 803 | 01 06 01 00 05 0000 630 | Муниципаль районнар милкендәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның башка рәвешләрен сатудан акчалар |
| **805** | **Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы** | |
| **805** | **01 00 00 00 00 0000 000** | **БЮДЖЕТ КЫТЛЫКЛАРЫН ЭЧКЕ ФИНАНСЛАУ ЧЫГАНАКЛАРЫ** |
| **805** | **01 02 00 00 00 0000 000** | **Россия Федерациясе валютасында кредит оешмалары кредитлары** |
| 805 | 01 02 00 00 05 0000 710 | Муниципаль районнарга Россия Федерациясе валютасында кредит оешмаларыннан кредитлар җәлеп итү |
| 805 | 01 02 00 00 05 0000 810 | Кредит оешмаларыннан муниципаль районнар тарафыннан кредитларын Россия Федерациясе валютасында түләп бетерү |
| **805** | **01 03 00 00 00 0000 000** | **Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджет кредитлары** |
| 805 | 01 03 01 00 05 0000 710 | Муниципаль районнар бюджетлары тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында кредитлар җәлеп итү |
| 805 | 01 03 01 00 05 0000 810 | Муниципаль районнар бюджетлары |

| | | |
|---|---|---|
| | | тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында кредитлар түләп бетерү |
| **805** | **01 05 00 00 00 0000 000** | **Бюджет чараларын исәпкә алу счетларында калган акчаларны үзгәртү** |
| 805 | 01 05 02 01 05 0000 510 | Муниципаль районнар бюджетларының башка калган акчаларын арттыру |
| 805 | 01 05 02 01 05 0000 610 | Муниципаль районнар бюджетларының башка калган акчаларын киметү |
| **805** | **01 06 00 00 00 0000 000** | **Бюджет кытлыкларын эчке финанслауның башка чыганаклары** |
| 805 | 01 06 04 01 05 0000 810 | Муниципаль гарантияләрне үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукы барлыкка килүгә китерсә яки бенефициарның принципалга карата таләп хокуклары гарантына юл кую белән бәйле булса, Россия Федерациясе валютасында муниципаль районнарның муниципаль гарантияләрен үтәү |
| 805 | 01 06 05 01 05 0000 540 | Муниципаль районнар бюджетларыннан юридик затларга Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары бирү |
| 805 | 01 06 05 01 05 0000 640 | Муниципаль районнар бюджетларыннан юридик затларга Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару |
| 805 | 01 06 05 02 05 0000 540 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына муниципаль районнар бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары бирү |
| 805 | 01 06 05 02 05 0000 640 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе валютасында муниципаль районнар бюджетларыннан бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару |